СОВЕТ
СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д. 52, с. Старое Чурилино,
Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яңа урам, 52 йорт, Иске Чүриле авылы,
Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48,3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Shur.Ars@tatar.ru

## Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карары

**"06" май 2024 ел** **№ 86**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезләмәләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 №131-ФЗ, «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәве турында» 13.07.2015 №218-ФЗ, «Хуҗасыз күчемсез мөлкәтне исәпкә алу тәртибен билгеләү турында» Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең 15.03.2023 № П/0086 боерыгы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибен (1 нче кушымта) расларга;
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән закон көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Чүриле авыл җирлеге
башлыгы урынбасары И. Н. Габдрахманов

Иске Чүриле
авыл җирлеге Советының
06.05.2024 ел, № 86
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибе (алга таба - Тәртип) «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законга, «Хуҗасыз күчемсез мөлкәтне исәпкә алу тәртибен билгеләү турында» Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең 2023 елның 15 мартындагы П/0086 номерлы боерыгына, «Күчемсез мөлкәтне исәпкә алу тәртибен билгеләү турында» 2023 елның 15 мартындагы 0086 номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә ачыкланган күчемсез мөлкәтне исәпкә алу һәм аны рәсмиләштерү тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Тәртип хуҗасыз яки хуҗасы билгесез булган яки милекчесе милек хокукыннан баш тарткан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориядә урнашкан күчемсез мөлкәткә кагыла.

1.3. Күчемсез мөлкәт объектларын хуҗасыз дип тану, хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектларын исәпкә кую һәм муниципаль милеккә кабул итү өчен документларны рәсмиләштерүне Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба - җирлек башкарма комитеты) әлеге Тәртип һәм Россия Федерациясе Граждан кодексы, башка норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашыра.

1.4. Хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектларын ачыклау, ачыкланган хуҗасыз мөлкәт объектларына муниципаль милек хокукын рәсмиләштерүнең төп максатлары һәм бурычлары түбәндәгеләр:

- файдаланылмый торган мөлкәтне ирекле граждан әйләнешенә җәлеп итү;
-мөлкәтне нормаль һәм имин техник эксплуатацияләүне тәэмин итү;
- муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеген төзекләндерү һәм аның территориясен тиешенчәкарап тоту;
- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясында билгеләнгән җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләрне хәл итү.

1.5. Әлеге Тәртип белән җайга салынмаган хуҗасыз күчемсез мөлкәтне муниципаль милеккә кабул итү мәсьәләләре Россия Федерациясенең гамәлдәге

законнары белән җайга салына.

## 2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау , аны исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибе

2.1. Хуҗасыз мөлкәт билгеләре булган күчемсез мөлкәт турындагы белешмәләр түбәндәгеләрдән керергә мөмкин:

- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан, прокуратурадан;
- инвентарьлаштыру нәтиҗәсендә;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы инженерлык инфраструктурасы объектларында ремонт эшләре башкарганда;
- юридик һәм физик затларның гаризалары нигезендә;
- башка ысуллар белән.

2.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә күчемсез мөлкәт объектларын ачыклау эшләрен оештыру Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы авыл җирлегенең Башлыгы (алга таба - җирлек башлыгы), яисә җирлекнең вәкаләтле башлыгы тарафыннан хуҗасыз милек билгеләре булган күчемсез мөлкәт турында белешмәләр нигезендә гамәлгә ашыра.

2.3. Хуҗасыз ачыкланган күчемсез мөлкәт объектларын исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.4. Күчемсез мөлкәт объекты турында мәгълүмат алынган көннән алып 10 эш көне эчендә җирлек башлыгы яки җирлек башлыгы тарафыннан вәкаләт бирелгән зат объектның урнашкан урынына барып, әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау акты төзи, кергән мәгълүматны тикшерә.

2.4. Хуҗасыз күчемсез мөлкәт ачыкланганнан соң, җирлек башкарма комитеты яки җирлек башлыгы тарафыннан вәкаләт бирелгән зат 10 эш көне эчендә хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектлары турында мәгълүматны төгәлләштерү һәм тулыландыру эшен башкара, күчемсез мөлкәт объектының милекчесе булмавын яисә милекчесе билгесез булуын, яисә милекче аңа милек хокукыннан баш тарткан булуын раслый торган документлар җыюны гамәлгә ашыра.

Күчемсез мөлкәт объектының милекчесе булмавын яки аның милекчесе билгесез булуын раслаучы документлар:

- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән әлеге күчемсез мөлкәт объектының федераль милек, Россия Федерациясе субъекты һәм муниципаль мөлкәт реестрларында исәпкә алынмавы турындагы документлар;
- хокуклар БТИ органнарында теркәлмәгән;
- күчемсез мөлкәткә хокукларны теркәү белән шөгыльләнүче тиешле дәүләт органнары (оешмалар) тарафыннан бирелгән, әлеге күчемсез мөлкәт

объектларына хокукның алар тарафыннан теркәлмәвен раслый торган документлар;

- күчемсез мөлкәткә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан һәм аның белән күчемсез мөлкәт объекты турындагы килешүләрдән белешмәләр.

2.5. Милекченең күчемсез мөлкәткә хокуктан баш тартуын раслый торган документ булып милекченең күчемсез мөлкәт объектына милек хокукыннан баш тартуы һәм әлеге мөлкәтне исәпкә куярга ризалыгы турында нотариаль яктан танықланган гаризасы тора (милекче бу мөлкәткә милек хокукыннан баш тарткан очракта тәкъдим ителә).

Милекче - юридик зат милек хокукыннан баш тарткан очракта, һәм, әгәр милек хокукы теркәлмәгән булса, җирлек башлыгы яки җирлек башлыгы тарафыннан вәкаләт бирелгән зат түбәндәге документларны соратып ала:

- милек хокукыннан баш тарткан затның милек хокукы булуын раслый торган хокук билгеле торган документларның күчермәләре;

- юридик затның гамәлгә кую документлары күчермәләре, юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык, салым түләүченең идентификация номеры.

Милекче - физик зат милек хокукыннан баш тарткан очракта, һәм, әгәр милек хокукы теркәлмәгән булса, җирлекнең башкарма комитеты яки җирлек башлыгы тарафыннан вәкаләт бирелгән зат ведомствоара хезмәттәшлек ярдәмендә түбәндәге документларны соратып ала:

- милек хокукыннан баш тарткан затның милек хокукы булуын раслый торган хокук билгели торган документларның күчермәләре;

- физик затны юридик зат булдырмаган эшмәкәр буларак теркәү турында мәгълүмат;

- гражданның шәхесен таныклый торган документ күчермәсе.

2.6. Күчемсез мөлкәт объекты милекчесе турында мәгълүмат алган очракта, тиешле объектны хуҗасыз мөлкәт сыйфатында исәпкә кую өчен документлар җыю эше туктатыла, бу хакта хуҗасыз мөлкәт турында белешмәләр биргән затка хәбәр ителә.

2.7. Күчемсез мөлкәт объекты турындагы белешмәләрне тикшерү чаралары тәмамланганнан соң 10 эш көне эчендә, әлеге Тәртипнең 2.6 пунктында күрсәтелгән очрактан тыш, күчемсез мөлкәт объектын хуҗасыз дип тану һәм аны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектлары реестрына (алга таба - Реестр) кертү турында җирлек башкарма комитеты карары чыгарыла.

2.8. Реестрны әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта белән расланган форма буенча җирлекнең башкарма комитеты алып бара.

2.9. Күчемсез мөлкәт объектын хуҗасыз дип тану турында җирлек башкарма комитеты карар кабул иткән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, җирлекнең башкарма комитеты кадастр, техник паспортлар һәм техник инвентарьлаштыру органнарына план әзерләүгә заказ бирә. Техник инвентарьлаштыру һәм кадастр һәм техник паспортлар әзерләү эшләре җирле бюджет акчалары исәбеннән башкарыла.

2.10. Хуҗасызлык билгеләре булган мөлкәтне җимерү (югалту) куркынычын булдырмау, гражданнарның тормышына һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч тудыручы авария хәлләре килеп чыгу һәм нәтиҗәләрен бетерү максатларында (тормышны тәэмин итү объектларын, инженерлык

инфраструктурасын һәм төзекләндерү объектларын тиешле хәлдә тоту өлешендә) җирлекнең башкарма комитеты әлеге мөлкәтнең саклануын бу максатларга бүлеп бирелгән җирле бюджет акчалары чикләрендә тәэмин итә.

Күрсәтелгән хуҗасыз мөлкәткә муниципаль милек хокукын таныганга кадәр, хуҗасыз җылылык челтәрләрен карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү "Җылылык белән тәэмин итү турында" 27.07.2010 №190-ФЗ Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

Үзәкләштерелгән кайнар су белән тәэмин итү системаларының, салкын су белән тәэмин итү һәм (яисә) су чыгару системаларының, шул исәптән суүткәргеч һәм канализация челтәрләренең үзәкләштерелгән объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, күрсәтелгән хуҗасыз мөлкәткә муниципаль милек хокукын таныганга кадәр яисә мондый объектларны Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә файдалануга алганга кадәр, милекче тарафыннан "Су белән тәэмин итү һәм су чыгару турында" 27.07.2010 №190-ФЗ Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.11. Ачыкланган күчемсез мөлкәт объектын исәпкә кую, "Хуҗасыз күчемсез мөлкәтне исәпкә алу тәртибен билгеләү турында" 15.03.2023 № П/0086 Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте боерыгы нигезендә, җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.12. Күчемсез мөлкәт объектын исәпкә куйганнан соң бер ел үткәч, җирлекнең башкарма комитеты мондый объектка муниципаль милек хокукын тану таләбе белән судка мөрәҗәгать итә.

Ачыкланган электр челтәре хуҗалыгы объектларын һәм башка линия объектларын исәпкә кую җирлек башлыгы яки вәкаләтле зат тарафыннан "Электр энергетикасы турында" 26.03.2003 №35-ФЗ Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

Линия объектларына карата хуҗасыз күчемсез мөлкәт исәпкә куелган көннән алып өч ай кыскартылган срок билгеләнгән, ул вакыт узганнан соң җирлек башлыгы яки җирлек башлыгы тарафыннан вәкаләт бирелгән зат муниципаль милек хокукын тану таләбе белән судка мөрәҗәгать итә ала.

2.13. Хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектларын муниципаль милеккә кабул итү әлеге Тәртипнең 2.12 пунктында күрсәтелгән гаризаны карау нәтиҗәләре буенча чыгарылган законлы көченә кергән суд карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.14. Күчемсез мөлкәткә хокукларны дәүләт теркәвенә алучы органда муниципаль милек хокукын дәүләт теркәвенә алу гамәлләре җирлекнең башкарма комитеты тарафыннан муниципаль милек хокукын тану турында суд карары законлы көченә кергән вакыттан алып 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

2.15. Муниципаль милек хокукын теркәгәннән соң, җирлекнең башкарма комитеты 10 эш көне эчендә объектны Реестрдан төшерү һәм аны муниципаль мөлкәт реестрына кертү буенча гамәлләр кыла.

2.16. Муниципаль милек хокукын теркәгәннән соң, башкарма комитет әлеге күчемсез мөлкәт объектлары астындагы җир кишәрлекләрен муниципаль милеккә рәсмиләштерү гамәлләрен кыла.

Хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау, исәпкә
алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү
тәртибенә 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау**
**АКТЫ**

"___"_______________

Минем тарафтан
__________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________
(ФИАи һәм вазыйфасы күрсәтелә)
__________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________
кергән гариза (мөрәҗәгать) нигезендә ________________________
( N ___) хуҗасызлык билгеләре булган күчемсез милек объекты тикшерелде.

Мөлкәтнең исеме _______________________________________________________

Милекнең урыны ____________________________________________

Милеккә кыскача характеристика _______________________________________________

Мөлкәтнең хуҗасыз мөлкәткә кертелергә мөмкин булган билгеләре _____________

__________________________________________________________________________

Мөлкәтнең элеккеге хуҗасы ___________________________________________________

Мөлкәт күпме вакыт хуҗасыз _________________________________________

Имза:

Хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау, исәпкә
алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү
тәртибенә 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегенең хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектлары**

| N т/б | Объектның исеме | Объект урнашкан урын | Объектка кыскача характеристика | Объектны хуҗасыз дип тану турында администрация карары номеры һәм датасы | Теркәүче органда исәпкә куюдатасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |